**ГЛАВА
БОЛЬШЕБИТАМАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422725, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Большой Битаман, ул. Московская, 2В

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ БИТАМАН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

422755, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Олы Битаман авылы, Мәскәү ур., 2В

Тел./факс: +7(84365) 62-8-47, e-mail: Bbit.Vsg@tatar.ru

**КАРАР**
**25 октябрь 2024 е.**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№ 9**

**Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегенең Олы Битаман торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 маддәсе нигезендә, 56 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Олы Битаман авыл җирлеге Уставының 24 статьясы һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2019 елның 23 октябрендәге 150 номерлы карары Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Олы Битаман авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында " Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Олы Битаман авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегенең Олы Битаман торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 12 ноябрендә 18.00 сәг Олы Битаман авылы, Мәскәү ур, 2В адресы буенча (Олы Битаман мәдәният йорты) уздырырга.

2. Җыенга түбәндәге мәсьәләләрне чыгарырга::

«Олы Битаман авылында яшәүче һәр балигъ булган гражданнан 2025 елда 500 сум күләмендә үзарасалым кертергә һәм түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- авыл җирлеген төзекләндерү (балалар уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру, декоратив үсемлекләр сатып алу)
- урамнарны яктырту (урам яктырткычлары сатып алу, урнаштыру)
- авыл эчендәге юлларны төзекләндереп тору (кышкы чорда юлларны кардан систарту, трактористка хезмәт хакы түләү, ягулык материаллары һәм запчастьләр сатып алу)
- авыл эчендәге юлларны төзекләндереп тору (вак таш сатып алу)

- авыл эчендәге юлларны төзекләндереп тору (вак таш түшәү)
- авыл территориясен төзекләндерү (агачлар кисү)
- каты коммуналь кадыклар урыннарын төзекләндерү (чүплекне юк итү)
- торак пункт территориясен төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/, https://pravo.tatarstan.ru адреслары буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар халыкка җиткергән көннән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы Сафина Г.Н.